Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2010 елның 27 августы № 43-198

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Югары Ослан районының Олы Мәми дәүләт авыл җирлеге башлыгы Н.А. Скарлухин докладын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Советы раслаганча, гамәлдәге кануннар үзгәрүгә бәйле рәвештә “Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты эшләнде, ул җирлек Советы тарафыннан хупланды, мәгълүмати стендларда халыкка җиткерелде һәм халык белән гавами тыңлауларда фикер алышуның барлык процедураларын узды.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының 19, 88-90 статьялары нигезендә

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставы мәкаләләренең яңа редакциясен расларга.
3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Н.А. Скарлухин

Олы Мәми авыл җирлеге Советының
2010 елның 27 августыннан
№ 43-198 карарына
1 Кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. Уставның 12 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. Муниципаль сайлаулар

1. Җирлектә муниципаль сайлаулар җирлек Советы депутатларын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын яшерен тавыш биреп, гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә сайлау максатларында уздырыла.

2. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутатын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары төзелә. Җирле үзидарәнең башка сайланулы органнары әгъзаларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары төзелә. Җирлек Советы депутатларын сайлаулар мәҗбүри, вакытлы була һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда уздырыла.

3. Тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты итеп тавыш бирү көненә 21 яшькә җиткән граждан җирлек Советы депутаты итеп сайланырга мөмкин.

Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә һәм законда билгеләнгән тәртиптә, Поселение территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарә органнарына сайлау һәм сайлану, Россия Федерациясе гражданнары кебек үк, күрсәтелгән сайлауларда бүтән сайлау гамәлләрендә катнашу хокукына ия.

4. Җирлек Советы депутатларын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлауларны әзерләү һәм уздыру гамәлдәге законнар нигезендә төзелә торган сайлау комиссияләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышларының иң күп санын алган кандидат сайланган дип таныла. Әгәр тавыш бирү бер кандидатура буенча үткәрелсә, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кимендә 50 процентын җыйган кандидат сайланган дип санала. Теркәлгән кандидатлар тавышларны бертигез җыйсалар, алданрак теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

6. Җирлек Советы депутатларын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлауларның йомгаклары рәсми рәвештә халыкка игълан ителергә тиеш.

7. Бермандатлы (яисә күпмандатлы) сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү, кандидатлар исемлекләре арасында һәм кандидатлар исемлекләре эчендә депутат мандатларын бүлешү, җирлекнең сайланулы органы әгъзаларын теркәү һәм сайлаулы вазыйфаи затны сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе гамәлдәге законнар белән билгеләнә».

2. Уставның 50 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек сайлау комиссиясе Җирлек советы тарафыннан федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә төзелә».

3. Уставның 50 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сайлау комиссиясенең вәкаләтләр чоры 5 ел тәшкил итә»

4. Уставның 90 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Җирлек Советы карары аларны кабул иткәннән соң, Җирлек башлыгы тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен муниципаль берәмлекләрне теркәү өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органына җибәрелә».

Совет рәисе,

Югары Ослан муниципаль районы

Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Н.А. Скарлухин